СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кооперативная, д. 22, с.Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22, E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Утар-Аты авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**“18” ноябрь 2019 ел** **№ 110**

**Утар-Аты авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында” 2017 елның 27 октябрендәге 43 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенең 31 бүлеге, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге Уставы нигезендә Утар-Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Утар-Аты авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында” 2017 елның 27 октябрендәге 43 номерлы карарына (Утар-Аты авыл җирлеге Советының 2019 елның 21 августындагы 99 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 3 пунктның 3.1.1 пунктындагы беренче абзацында «автомобиль юллары» сүзләреннән соң «, әлеге карарның 2 пунктындагы 2.1 пунктчасында күрсәтелгәннәрдән тыш, " сүзләрен өстәргә»;

2) 4 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасының гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән бер ай үткәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г. Мөхәммәтгалиева